# МИЛӘШКӘЕМ

*М.МИНҺАҖЕВ көе*
*А.ХАМЗИН шигыре*

Өй картындагы миләшем –
Минем якын сердәшем.
Чуалса фикер - хисләрем,
Аның белән сөйләшәм.

*КУШЫМТА:*
Миләшкәем, хәлең ничек,
Бармы әллә зарларың?
Сөйлә миңа, яшермичә,
Иң кадерле уйларың.
Миләшкәем.

Иңнәреңә сөялэм дә
Күзләреңә текәләм.
Юксынуга сер бирмичә
Көтәсеңне мин беләм.

Аңлый мине миләшкәем,
Авыр кичерешләрем.
Көзге кырау балландырды
Аның да җимешләрен.